СОВЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2023 елның 5 мае № 28/4

«Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль милкендәге мөлкәтне арендага бирү тәртибе турында» нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт яки муниципаль мәдәният оешмаларына хуҗалык алып бару яки оператив идарә итү хокукында беркетелгән, дәүләт яки муниципаль милеккә карата конкурслар яки аукционнар үткәрмичә генә аренда шартнамәләрен төзү кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 9 сентябрендәге 1529 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль милкендә булган мөлкәтне арендага бирү тәртибе турында» 2010 елның 29 октябрендәге 2/2 номерлы карары белән расланган нигезләмәгә, **1.5 пунктны түбәндәге эчтәлектәге дүртенче абзац** белән тулыландырып, үзгәреш кертергә:

«Мәдәният оешмасы тарафыннан мөлкәтне арендага бирү федераль мәдәният оешмаларына карата – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2004 елның 3 декабрендәге 739 номерлы «Федераль дәүләт унитар предприятиесе мөлкәте милекчесенең хокукларын гамәлгә ашыру буенча федераль башкарма хакимият органнары вәкаләтләре турында» карары белән каралган, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 10 октябрендәге 662 номерлы «Федераль автоном учреждениене гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен федераль башкарма хакимият органнары тарафыннан гамәлгә ашыру турында нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган, Федераль автоном учреждениене гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен федераль башкарма хакимият органнары тарафыннан гамәлгә ашыру турында нигезләмә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 июлендәге 537 номерлы «Федераль дәүләт учреждениесен гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен федераль башкарма хакимият органнары тарафыннан гамәлгә ашыру тәртибе турында» карары нигезендә, Россия Федерациясе субъектларының мәдәният оешмаларына карата – Россия Федерациясе субъектлары законнары белән, муниципаль мәдәният оешмаларына карата – җирле үзидарә органнарының норматив

хокукый актлары белән каралган очракларда һәм тәртиптә мөлкәт хуҗасы һәм аны гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы орган белән килештерелергә тиеш».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы, Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе — М.Р. Гафаров